**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

# КАРАР

«13» 04 2020 ел Яр Чаллы № 1223

Татарстан Республикасының спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы физкультура-спорт оешмалары хезмәткәрләренә – яшь белгечләренә акчалата түләүләр билгеләү турында

Яшь белгечләргә дәүләт ярдәме күрсәтү һәм Татарстан Республикасында спорт резервын әзерләүче физкультура оешмалары белгечләрен Татарстан Республикасының Тукай муниципаль районында беркетү максатыннан, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы физкультура-спорт оешмалары хезмәткәрләренә – яшь белгечләренә акчалата түләүләр билгеләү турында» 2019 елның 31 октябрендәге 979 номерлы карарына таянып,

**КАРАР БИРӘ:**

1. Татарстан Республикасының спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы муниципаль физкультура-спорт оешмаларында эшләүче хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә түбәндәге акчалата түләүләрне билгеләргә:

эшләнгән вакытка пропорциональ рәвештә 1 111 сум күләмендә айлык стимуллаштыручы өстәмә түләү, әмма айга 1 111 сумнан да артмаган күләмдә;

хуҗалык төзекләндерүгә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү 20 000 сум күләмендә.

2. Татарстан Республикасының спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы муниципаль физкультура-спорт оешмаларында эшләүче хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә акчалата түләүләр бирү тәртибен расларга.

3. Татарстан Республикасының спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы муниципаль физкультура-спорт оешмаларында эшләүче хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә акчалата түләүләрне башкаруга Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибен расларга.

4. Әлеге карар, Татарстан Республикасының спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы муниципаль физкультура-спорт оешмаларында эшләүче хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә акчалата түләүләр бирү тәртибе, Татарстан Республикасының спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы муниципаль физкультура-спорт оешмаларында эшләүче хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә акчалата түләүләрне башкаруга Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы Тукай

муниципаль районы бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибе нигезләмәләре 2020 елның 1 январеннән үз көченә керә.

5. ТР Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 17 январендәге 55 номерлы карары үз көчен югалткан дип санарга.

6. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре, спорт һәм туризм бүлегенә Татарстан Республикасының спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы физкультура-спорт оешмалары хезмәткәрләренә – яшь белгечләренә акчалата түләүләр турында килешү төзүне тәэмин итәргә.

7. Әлеге карарны районның рәсми сайтында һәм ТР рәсми хокукый мәгълүмат порталында урнаштырырга.

8. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары И.Ш. Бариевка йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе Л.Г. Авзалов

Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 2020 елның 13.04 1223 номерлы карарына 1 нче кушымта

Татарстан Республикасының спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы муниципаль физкультура-спорт оешмаларында эшләүче хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә акчалата түләүләр бирү тәртибе

1. Әлеге тәртип Татарстан Республикасының спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы муниципаль физкультура-спорт оешмаларында эшләүче хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә түбәндәге акчалата түләүләрне билгеләү тәртибен һәм шартларын билгели:

эшләнгән вакытка пропорциональ рәвештә 1 111 сум күләмендә айлык стимуллаштыручы өстәмә түләү, әмма айга 1 111 сумнан да артмаган күләмдә;

хуҗалык төзекләндерүгә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү 20 000 сум күләмендә.

2. Оешма хезмәткәрләренә – яшь белгечләргә айлык стимуллаштыручы өстәмәне түләү Татарстан Республикасы бюджетында тиешле финанс елына Татарстан Республикасы Спорт министрлыгына (алга таба – Министрлык) каралган акчалар хисабына башкарыла.

3. Оешманың хезмәткәре – яшь белгече дип, һөнәри белем бирү оешмасын, югары белем бирү программалары - бакалавриат, специалитет, магистратура - буенча дәүләт аккредитациясе алган югары белем бирү оешмасын (алга таба – һөнәри белем бирү оешмасы яки югары белем бирү мәгариф оешмасы) беренче тапкыр көндезге формада тәмамлаган һәм һөнәри белем бирү оешмасы яисә югары белем бирү мәгариф оешмасын тәмамлау елының 1 ноябреннәннән дә соңга калмыйча, һөнәри белем дәрәҗәсе һәм квалификациясе нигезендә хезмәт шартнамәсе буенча оешмага түбәндәге вазыйфаларга эшкә алынган 30 яшькә кадәр булган Россия Федерациясе гражданы танылa: физик культура буенча инструктор, педагог-оештыручы, педагог-психолог, адаптив физик культура буенча инструктор-методист, адаптив физик культура буенча өлкән инструктор-методист, тренер, адаптив физик культура буенча тренер-укытучы, хореограф, тренировка процессы администраторы, адаптив физик культура буенча өлкән тренер-укытучы.

4. Айлык стимуллаштыручы өстәмә түләү хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә эшкә урнашу аеннан соң килүче айның 1 числосыннан әлеге тәртипнең 3 пунктында күрсәтелгән вазыйфада беренче өч ел дәвамында өзлексез эшләгәндә билгеләнә.

Хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә айлык стимуллаштыручы өстәмә түләүне билгеләү, туктату, озайту турында карар оешма боерыгы белән раслана.

Хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә айлык стимуллаштыручы өстәмәне түләү түбәндәге чорга озайтыла:

– Россия Федерациясе Кораллы көчләрендә чакырылыш буенча хезмәт итү яки альтернатив граждан хезмәте;

– йөклелек һәм бала табу буенча ял, өч яшькә җиткәнче бала карау ялы;

– көндезге формада аспирантурада уку.

5. Хезмәткәр – яшь белгеч башка оешмага әлеге тәртипнең 3 пунктында күрсәтелгән вазыйфага күчкәндә, эштә 30 көннән дә артмаган ял вакыты рөхсәт ителә.

6. Штат саны кимү яки штат кыскару белән бәйле рәвештә, хезмәткәр – яшь белгеч эштән азат ителгәндә, алга таба башка оешмага әлеге тәртипнең 3 пунктында күрсәтелгән вазыйфага эшкә урнашканда, 60 көннән дә артмаган ял вакыты рөхсәт ителә.

7. Хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә айлык стимуллаштыручы өстәмә түләү яшь белгечнең төп эш урыны буенча гына билгеләнә.

8. Хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә айлык стимуллаштыручы өстәмә түләү төп вазыйфа буенча һәм әлеге хезмәткәр – яшь белгеч тарафыннан эш бер үк вакытта башкару шартларында гамәлгә ашырылган вазыйфа буенча, ләкин 1 ставкадан артмаган күләмдә билгеләнә.

9. Хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә айлык стимуллаштыручы өстәмә түләү күләме түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$D = P \times \frac{H_f}{H_n},$$

биредә:

D – хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә айлык стимуллаштыручы өстәмә түләү күләме, сумнарда;

P – хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә 1 111 сум күләмендә айлык стимуллаштыручы өстәмә түләү;

$H_f$ - хезмәткәрләр – яшь белгечләр тарафыннан фактта эшләнгән вакыт, сәгатьтә;

$H_n$ - спорт резервын әзерләүче оешма хезмәткәрләре хезмәт хакының база ставкасы өчен сәгать нормасы, сәгатьтә.

10. Хуҗалык төзекләндерүгә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү хезмәткәргә бер тапкыр бирелә.

11. Хезмәткәр, һөнәри белем бирү оешмасын яисә югары белем бирү оешмасын тәмамлаганнан соң эшкә урнашкан оешмада эшли башлаганнан соң, министрлык тарафыннан расланган форма буенча оешма җитәкчесе исеменә хуҗалык төзекләндерүгә бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү билгеләү турында гариза белән мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

12. Хуҗалык төзекләндерүгә бер мәртәбә акчалата түләү алу шарты булып хезмәткәрнең һөнәри белем бирү оешмасы яки югары белем бирү мәгариф оешмасы тәмамлаганнан соң эшкә урнашкан оешмада ике ел дәвамында төп эш урыны буенча эшләү йөкләмәсе тора.

Хезмәт килешүе туктатылган очракта, аны эшкә алган көннән алып ике ел вакыт узганчыга кадәр, ул бер тапкыр түләнә торган акчалата түләүнең бер өлешен, күрсәтелгән срок тәмамланганчы калган фактта эшләнмәгән вакытка пропорциональ рәвештә кире кайтарырга тиеш.

13. Оешмалар ай саен агымдагы айның 5 числосына кадәр Министрлыкка түбәндәге документларны тапшыралар:

- министрлык тарафыннан расланган форма буенча акчалата түләүләрне бирү турында гариза;

- министрлык боерыгы белән расланган форма буенча оешма хезмәткәрләре – яшь белгечләренең реестрлары.

14. Министрлык әлеге тәртипнең 13 пунктында күрсәтелгән документларны, кергән көннән 5 эш көне эчендә карый.

Оешма әлеге тәртипнең 13 пунктында күрсәтелгән документларның тулы булмаган пакетын яки әлеге тәртипнең 13 пункты таләпләренә туры килми торган документларны тапшырган очракта, министрлык гаризаны кире кайтара һәм биш көн эчендә кире кайтару сәбәпләрен күрсәтеп, оешмага хәбәр итә.

Оешма гаризаны кире кайтару турында хәбәрнамәне алган көннән, әлеге тәртиптә билгеләнгән таләпләрне үтәү шарты белән, әлеге тәртипнең 11 пунктында күрсәтелгән документларны кабат тапшыра.

15. Хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә акчалата түләүләрне башкару өчен оешма чыгымнарын финанс белән тәэмин итү Министрлык тарафыннан күрсәтелгән максатларга субсидия бирү юлы белән гамәлгә ашырыла. Субсидия Министрлык һәм оешма арасында төзелә торган килешү нигезендә Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан расланган типлаштырылган форма нигезендә (алга таба - килешү) бирелә.

Килешү әлеге тәртипнең 13 пунктында күрсәтелгән документларны тапшырган көннән 10 көн эчендә төзелә.

16. Министрлык ай саен хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә оешмаларның Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында ачылган шәхси счетларына акчалата түләүгә субсидияләр күчерә.

17. Оешмалар килешүдә каралган сроклар һәм форма нигезендә хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә акчалата түләүгә субсидияләрне файдалану турында министрлыкка хисап тапшыралар.

18. Агымдагы финанс елында оешма тарафыннан файдаланылмаган субсидияләр Татарстан Республикасы бюджетына билгеләнгән тәртиптә күчерелергә тиеш.

19. Оешма тарафыннан субсидияләр бирү шартларын бозган очракта, субсидияләр министрлыкның язма таләбе нигезендә тиешле таләп алынган көннән 10 эш көне эчендә билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы бюджетына кайтарылырга тиеш.

20. Субсидияләр бирү шартларын, шулай ук төзелгән килешүләрнең үтәлешен контрольдә тоту Министрлык һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан башкарыла.

21. Оешмалар ай саен оешмалар тарафыннан билгеләнгән хезмәт хакын түләү вакытында хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә акчалата түләүләрне түләүне тәэмин итәләр.

Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының 20*20* елның *13.04* *1223* номерлы карарына 2 нче кушымта

Татарстан Республикасының спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы муниципаль физкультура-спорт оешмаларында эшләүче хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә акчалата түләүләрне башкаруга Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирү тәртибе

1. Әлеге тәртип Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы «Спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесендә эшләүче яшь белгечләргә акчалата түләүләрне гамәлгә ашырганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен тулысынча финанслау максатында Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирү кагыйдәләрен, максатларын һәм шартларын билгели (алга таба - башка бюджетара трансфертлар, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы).
2. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы бюджетына башка бюджетара трансфертлар Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы территориясендә физик культура һәм массакүләм спорт үсеше өчен шартлар булдыру буенча Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты вәкаләтләрен башкарганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районың «Спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесендә эшләүче, Татарстан Республикасы спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы яшь белгечләргә акчалата түләүләрне башкару өлешендә тулы күләмдә финанслашу максатында бирелә.
3. Әлеге тәртип нигезендә бирелә торган бюджет ассигнованиеләрен баш бүлүче булып Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы (алга таба – Министрлык) тора
4. Башка бюджетара трансфертлар Министрлыкка тиешле финанс елына җиткерелгән бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә әлеге тәртипнең 2 пунктында күрсәтелгән максатларга бирелә.
5. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районын Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районында Татарстан Республикасы спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы, түбәндәге вазыйфаларда эшләүче хезмәткәрләре булган муниципаль физкультура спорт оешмалары башка бюджетара трансфертлар алу өчен сайлап алу критерие булып тора: физкультура буенча инструктор, педагог-оештыручы, педагог-психолог, адаптив физик культура буенча инструктор-методист, адаптив физик культура буенча өлкән инструктор-методист, тренер, адаптив физик культура буенча тренер-укытучы, хореограф, күнегүләр процессы администраторы, адаптив физик культура буенча өлкән тренер-укытучы.
6. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы бюджетына башка бюджетара трансфертлар түбәндәге шартларда бирелә:

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты норматив хокукый акты белән расланган Татарстан Республикасы спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районыны «Спорт мәктәбе» муниципаль бюджет учреждениесендә эшләүче хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә башка бюджетара трансфертлар хисабына акчалата түләүләр бирү тәртибе булу;

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге бюджетында (Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге бюджетының җыелма бюджет язмасында) финанслашу максатларында башка бюджетара трансфертлар бирелә торган муниципаль берәмлекнең чыгым йөкләмәләрен үтәүгә аларны үтәү өчен кирәкле күләмдә бюджет ассигнованиеләре булу;

әлеге тәртипнең 10 пункты нигезендә башка бюджетара трансфертлар бирү турында Министрлык белән килешү төзү.

7. Тиешле финанс елына Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетлары арасында башка бюджетара трансфертларны бүлү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив хокукый акты белән раслана.

8. Тиешле финанс елына (Si) Тукай муниципаль районына бирелә торган башка бюджетара трансфертлар күләме түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$S_i = D \times K_{ip} \times 12 + P \times K_{ir} + C_i,$$

биредә:

D - Тукай муниципаль районы территориясендә урнашкан Татарстан Республикасы спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы муниципаль физкультура-спорт оешмаларында эшләүче хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә 1111 сум күләмендә айлык стимуллаштыручы өстәмә түләү;

12 - елдагы айлар саны;

$K_{ip}$ - Тукай муниципаль районы территориясендә урнашкан Татарстан Республикасы спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы муниципаль физкультура-спорт оешмаларында эшләүче хезмәткәрләрнең – яшь белгечләрнең акчалата түләү алырга хокуклы план саны;

P - Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы территориясендә урнашкан Татарстан Республикасының спорт резервын әзерләүче муниципаль физкультура спорт оешмаларында эшләүче яшь белгечләргә хуҗалык төзекләндерүгә 20 000 сум күләмендә бер мәртәбә акчалата түләү;

$K_{ir}$ - Тукай муниципаль районы территориясендә урнашкан Татарстан Республикасы спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы муниципаль физкультура-спорт оешмаларында эшләүче хезмәткәрләрнең – яшь белгечләрнең бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүне алырга хокуклы план саны;

$C_i$ - Тукай муниципаль районы территориясендә урнашкан Татарстан Республикасы спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы муниципаль физкультура-спорт оешмаларында эшләүче хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә хезмәт өчен түләү буенча чыгымнар.

9. Тиешле календарь аена (Sim) финанслауның иң чик күләмнәрен Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы бюджетына җиткерү өчен башка бюджетара трансфертлар күләме түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$S_{im} = D \times K_{ipm} + P \times K_{irm} + C_{im},$$

биредә:

$K_{ipm}$ - Тукай муниципаль районы территориясендә урнашкан Татарстан Республикасының спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы муниципаль физкультура-спорт оешмаларында эшләүче хезмәткәрләрнең – яшь белгечләрнең акчалата түләү алырга хокуклы фактгагы саны, агымдагы айның 1 числосы торышына;

$K_{irm}$ - Тукай муниципаль районы территориясендә урнашкан Татарстан Республикасының спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы муниципаль физкультура-спорт оешмаларында эшләүче хезмәткәрләрнең – яшь белгечләрнең бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүне алырга хокуклы хокуклы фактгагы саны, агымдагы айның 1 числосы торышына;

$C_{im}$ - Тукай муниципаль районы территориясендә урнашкан Татарстан Республикасының спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы муниципаль физкультура-спорт оешмаларында эшләүче хезмәткәрләргә – яшь белгечләргә хезмәт өчен түләү буенча чыгымнар, агымдагы айга.

10. Башка бюджетара трансфертлар Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты арасында төзелә торган башка бюджетара трансфертлар бирү турындагы килешү (алга таба - килешү) нигезендә тиешле финанс елның 25 гыйнвареннан соңга калмыйча бирелә, анда түбәндәгеләр карала:

башка бюджетара трансфертларның максатчан билгеләнеше;

бирелә торган башка бюджетара трансфертлар күләме;

башка бюджетара трансфертларны күчерү сроклары;

башка бюджетара трансфертлардан файдалануның нәтиҗәлелеге күрсәткечләре;

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең башка бюджетара трансфертлардан максатчан файдалануын контрольдә тоту;

башка бюджетара трансфертларны алучы тарафыннан финанс белән тәэмин итү чыганагы булган башка бюджетара трансфертлар чыгымнарны гамәлгә ашыру турында һәм башка бюджетара трансфертларны куллануның нәтиҗәлелек күрсәткечләрен үтәү турында хисап тапшыру тәртибе, формасы һәм сроклары;

әлеге тәртиптә билгеләнгән шартлар бозылган очракта, килешүне өзү тәртибе;

якларның җаваплылыгы.

11. Башка бюджетара трансфертлардан файдалануның нәтиҗәлелеген бәяләү башка бюджетара трансфертлардан файдалануның максатчан күрсәткечләре (нәтиҗәләре) нигезендә гамәлгә ашырыла.

12. Башка бюджетара трансфертларны куллану нәтиҗәлелегенең (нәтиҗәсе) максатчан күрсәткече булып физкультура-спорт юнәлешендәге һөнәри белем бирү оешмаларын яисә югары белем бирү оешмаларын тәмамлаган, алган белгечлек буенча спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы муниципаль физкультура-спорт оешмаларында эшләүче хезмәткәрләрнең – яшь белгечләрнең тиешле финанс елына исемлек буенча уртача саны тора.

13. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итүгә (аны финанслашу максатларында башка бюджетара трансфертлар бирелә) Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы бюджетының бюджет ассигнованиеләре күләме килешүдә билгеләнгән башка бюджетара трансфертларны куллануның нәтиҗәлелек күрсәткечләренә (нәтиҗәләренә) ирешү зарурлыгыннан чыгып, җирле бюджет турында (Татарстан

Республикасы Тукай муниципаль районы бюджетының җыелма бюджет язмасы белән билгеләнә) карар белән раслана.

14. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты Министрлык боерыгы белән расланган форма буенча Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге территориясендә урнашкан Татарстан Республикасының спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы муниципаль физкультура спорт оешмаларында эшләүче хезмәткәрләр – яшь белгечләр реестрын алып бара һәм ай саен, агымдагы айның 5 числосыннан да соңга калмыйча, Министрлыкка реестрны һәм башка бюджетара трансфертлар бирү өчен гаризаны тапшыра.

15. Министрлык Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре территориясендә урнашкан Татарстан Республикасы спорт резервын әзерләүне гамәлгә ашыручы муниципаль физкультура спорт оешмаларында эшләүче хезмәткәрләрнең – яшь белгечләрнең җыелма реестрын алып бара һәм ай саен, агымдагы елның 15 числосыннан да соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына башка бюджетара трансфертлар бирү өчен гариза бирә.

16. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы, Министрлык гаризасы кергән көннән соң биш эш көненнән дә соңга калмыйча, күрсәтелгән максатларга финанслауның иң чик күләмнәрен җиткерү өчен, Министрлыкка чыгым расписаниесен җибәрә.

17. Министрлык күрсәтелгән максатларга финанслауның иң чик күләмнәрен җиткергән көннән алып биш эш көненнән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы бюджеты акчаларын исәпкә алу өчен Россия Банкының бүлекчәләрендә ачылган Татарстан Республикасы буенча Федераль казначылык идарәсе исәп-хисап счетына башка бюджетара трансфертларны күчерә.

18. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты ай саен, хисап чорыннан соң килүче айның 15 числосыннан да соңга калмыйча, Министрлыкка башка бюджетара трансфертлар финанс белән тәэмин итү чыганагы булган чыгымнар һәм килешүдә каралган форма һәм тәртип буенча башка бюджетара трансфертларны кулланунының нәтиҗәлелек күрсәткечләрен үтәү турында хисап тапшыра.

19. Татарстан Республикасы спорт министрлыгы ай саен, хисап чорыннан соң килә торган айның 20 числосыннан да соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Финанс министрлыгына Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре бюджетларының башка бюджетара трансфертлар финанс белән тәэмин итү чыганагы булган чыгымнары һәм килешүдә каралган форма һәм тәртип буенча башка бюджетара трансфертларны кулланунының нәтиҗәлелек күрсәткечләрен үтәве турында хисап тапшыра.

20. Башка бюджетара трансфертлар бирү елының 31 декабренә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы әлеге тәртипнең 12 пунктында каралган күрсәткечкә ирешмәгән очракта, Тукай муниципаль районы бюджетыннан Татарстан Республикасы бюджетына башка бюджетара трансфертлар бирү елыннан соң килүче елның 1 мартына кадәр кире кайтарылырга тиешле акчалар күләме ($V_{возврата}$) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$V_{возврата} = V_{мбт} \times k \times 0{,}1,$$

биредә:

$V_{мбт}$ - хисап финанс елында муниципаль берәмлек бюджетына бирелгән башка бюджетара трансфертлар күләме;

k - башка бюджетара трансфертларны кире кайтару коэффициенты.

21. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы бюджетыннан Татарстан Республикасы бюджетына хисап финанс елында (Vмбт) Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге бюджетына бирелгән башка бюджетара трансфертлар күләмендә кире кайтарылырга тиешле акчалар күләмен исәпләгәндә, башка бюджетара трансфертлар бирү елыннан соң килә торган елның 1 январена файдаланылмаган башка бюджетара трансфертларның күләме исәпкә алынмый.

22. Башка бюджетара трансфертларны кире кайтару коэффициенты (k) түбәндәге формула буенча билгеләнә:

$$k = 1 - \frac{T}{S},$$

биредә:

T - башка бюджетара трансферттан файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткеченең ел ахырына фактта ирешелгән зурлыгы;

S - башка бюджетара трансфертлардан файдалану нәтиҗәлелеге күрсәткеченең килешүдә билгеләнгән пландагы зурлыгы.

23. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы тарафыннан башка бюджетара трансфертлар бирү шартлары бозылган очракта, шул исәптән Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы тарафыннан әлеге тәртипнең 20 пункты нигезендә Татарстан Республикасы бюджетына акчалар кире кайтарылмаган очракта, аңа Россия Федерациясе бюджет законнарында каралган мәҗбүриләү чаралары кулланыла.

24. Агымдагы финанс елының 1 январена кулланылмаган башка бюджетара трансфертлар агымдагы финанс елының беренче 15 эш көне дәвамында Татарстан Республикасы бюджеты кеременә кире кайтарылырга тиеш.

Башка бюджетара трансфертларның файдаланылмаган калдыгы Татарстан Республикасы бюджеты кеременә күчерелмәгән очракта, күрсәтелгән акчалар Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы билгеләгән тәртиптә, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән гомуми таләпләрне үтәп, Татарстан Республикасы бюджеты кеременә алынырга тиеш.

Әлеге тәртип нигезендә бирелгән, хисап финанс елында кулланылмаган башка бюджетара трансфертларга ихтыяҗ булу турында министрлык карары нигезендә күрсәтелгән башка бюджетара трансфертлар калдыгыннан артмаган күләмдәге акчалар, агымдагы финанс елында күрсәтелгән башка бюджетара трансфертларны бирү максатларына туры килә торган муниципаль берәмлек бюджеты чыгымнарын финанс белән тәэмин итү өчен, Тукай муниципаль районы бюджеты кеременә кире кайтарылырга мөмкин.

24. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты тапшырыла торган хисап белешмәләренең дөрес булмавы һәм башка бюджетара трансфертлардан максатчан файдаланмаган өчен законнар нигезендә җаваплы.

25. Башка бюджетара трансфертларның максатчан кулланылышын контрольдә тоту Татарстан Республикасы Спорт министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.